ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

15 февраль 2019 ел №133

Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлеге «15» март, 2014 ел 63 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалткан дип санарга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Дәвеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Дәвеш авыл җирлеге башлыгы Т.Т. Хөсәенов